


**Тәрбиячеләр көне белән!** **/Котлыйбыз!/**

Тәрбияче апаларыбызны чын күңелдән һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйбыз! Тәрбияче һөнәре – җаваплы һәм фидакарь хезмәт. Ул көч - энергия һәм бик зур сабырлык сорый. Сезнең кулларда – киләчәк буын. Сез нәни балалар алдында бәхетле балачак һәм хыяллар иленә ишекләр ачасыз. Аларга тиешле белем һәм тәрбия бирәсез, сәләтләрен ачарга һәм аларны үстерергә ярдәм итәсез. Бәйрәм белән сезне, тәрбиячеләр! Сезгә нык сәламәтлек, сабырлык, иҗади уңышлар телибез.

*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*

## Безнең «Беренче математик» /Безнең уңышлар/

21 сентябрь көнне Аксубай районында 4-7 сыйныф укучылары өчен «Беренче математик» олимпиадасы булып узды. Чара өч мәктәп базасында оештырылды: Аксубайның 3 нче урта мәктәбендә (100 укучы), «Иске Ибрай урта мәктәбе»ндә (49 укучы) һәм «Иске Кыязлы урта мәктәбе»ндә (13 укучы).Уку елы башында оештырылган олимпиада укучыларга һәм аларның әти-әниләренә мавыктыргыч математика дөньясы белән танышу һәм дәрестән тыш дәресләр турында уйлану өчен менә дигән мөмкинлек бирде. «Беренче математик» ның төп максаты – өлгерешне тикшерү түгел, ә стандарт булмаган фикерләүне күрсәтү, математиканы алга таба өйрәнүгә кызыксыну уяту һәм үз көченә ышанычны ныгыту. Биремнәр һәр бала, әзерлек дәрәҗәсенә карамастан, биремнәрне чишүдә азарт сизсен һәм үзенең математик потенциалын ача алсын өчен төзелде. Олимпиада укучыларны төрле математика активлыкларына һәм түгәрәкләр, турнирлар һәм башка олимпиадалар оештырган чараларга җәлеп итү мәйданчыгына әверелде.



Әлеге чарада безнең мәктәп укучылары да катнашты.Шулар арасыннан 6нчы сыйныф укучысы **Гыйниятуллин Азамат** лаеклы **III урынны** алды. Без аңа киләсе бәйгеләрдә дә катнашып, яңа җиңүләргә ирешүен телибез.

***Алсу Сафиуллина, математика укытучысы***

**/Безнең сәяхәтләр/**



## Көзге урманга сәяхәт

Безнең мәктәп өчен елның төрле фасылында табигатькә чыгып ял итү, рухи азык туплау яңалык түгел. Быел да сентябрьнең бик матур көнендә көзге урманга сәфәргә чыктык.

Табигатькә чыгу – вакытны кызыклы үткәрү ысулы гына түгел, ә тормыш өчен кирәкле төрле күнекмәләр алу мөмкинлеге дә. Мондый экскурсияләрдә кырга чыкканда дәрес киенергә, учак кабызырга, ашарга пешерү күнекмәләренә өйрәнәбез. Болында телефоннарыбыздан аерылып рәхәтләнеп хәрәкәтле уеннар уйныйбыз. Табигатьнең төрле агач ботакларыннан, төрле төстәге яфракларыннан көзге композиция дә ясыйбыз. Шул арада апа-абыйларыбыз пылау пешереп, җимешләрдән компот кайнатып безне ашарга да чакыралар. Учакта пешкән бәрәңге бигрәк тә тәмле булды. Көнебез бик күңеллле һәм файдалы үтте. Барыбыз да бергә рәхәтләнеп саф һавада төрле уеннар уйнадык, көзге матурлыкны күзәттек, үзара аралаштык. Мәктәбебез директоры Рафик абый безне әлеге урыннарның атамалары белән таныштырды. Әлеге көн безнең күңелдә матур бер мизгел булып уелып калды.

***Ләйсән Закирова, VIII сыйныф укучысы***

**/Безнең спорт/**



9 сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** Яр Чаллыда узган шахмат уенының блиц төре буенча Татарстан Республикасы команда чемпионатында катнашты. Аның уены команда өчен шактый өстенлек тәэмин итте һәм коллективның гомуми уңышына өстәмә булды. Беренчелекне алган Фаилгә алдагы бәйгеләрдә дә зур уңышлар теләп калабыз!

**/Котлыйбыз!/**

Сентябрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз – I сыйныфтан **Елисеев Аделне** (15.09), VIII сыйныфтан **Төхфәтуллин Камилне** (26.09) туган көннәре белән котлап, акыллы, сау-сәламәт булып, тырышып укуларын теләп калабыз.

9нчы сентябрьдә гомер бәйрәмен билгеләп үтүче директорыбыз **Рафик абый Насыйровны** да туган көне белән котлап, авыр, җаваплы хезмәтендә уңышлар, сәламәтлек, гаилә иминлеге телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Каусәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева**

# Мәктәп хәбәрчесе

**№7**
**(№68)**
**сентябрь**
**2025 ел**

**Түбән Майна урта мәктәбе газите**

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**



**/Мөхәррир минбәре/**

## Беренче кыңгырау – белем бәйрәме

Ел саен сентябрьнең беренче иртәсендә мәктәп ишегалды балаларның шат авазына, матур көйләргә күмелә. Менә шушы күңелле бәйрәм белән яңа уку елы башланып китә. Беренче сентябрь – укучылар һәм укытучылар бәйрәме генә түгел, белемнең кадерен белгән һәр кеше өчен дә зур тантана. Бигрәк тә кечкенә генә авылда урта мәктәп ишегалдында кыңгырау авазын ишетү – шатлыкның шатлыгы инде ул!

Быел да беренче кыңгырау авазы мәктәпнең 39 укучысы өчен чыңлады. I сыйныфка 1 баланы – Елисеев Аделне кабул иттек. Кызганыч, быелгы Белем бәйрәмен төп чараны XI сыйныф укучылары алып бармады.Чөнки ике ел рәттән инде IX сыйныфны тәмамлаучылар төп белем аттестатын алып, һөнәри белем бирүче көллиятләргә, техникумнарга юл тота.

Мәктәптә күпме укучы булуга карамастан, барысы өчен дә максат бер –төпле белем алырга! Бәйрәм тантанасын ачканда директорыбыз Насыров Рафик Гомәр улы һәр укучыга тәртипле, тырыш, максатчан булып, белем үрләрен яуларга чакырды.I сыйныф укучысы Аделгә тәүге китабын – Әлифбаны тапшырганда аның туган җиребез өчен кирәкле шәхес булып үсүен теләде. Район үзәгеннән килгән вәкил Флүн Җәмил улы Зәйнуллин укучыларны мәктәптә тырышып укып, үз төбәгебез өчен кирәкле белгечләкләр алырга чакырды. Ветеран мөгаллимнәребез дә бәйрәм түренә чыгып, балаларга һәм мөгаллимнәргә үз хәер-фатихаларын юлладылар. Рафик абый Исмәгыйлов бәйрәм саен үз иҗатыннан булган шигырен укып китте.



Бәйрәмдә ясалган һәрбер чыгыш балаларга изге теләктән генә тора. Шушы теләкләр кабул булыр, барлык укучылар белем алуга бар күңелләрен бирерләр дип ышанаса килә. Әти-әниләргә дә, укытучылар белән берлектә, балаларының энә белән кое казу эшендә һәрдаим ярдәм итеп торуларын телибез. Бердәм булып башкарылган хезмәт барча авырлыкларны да җиңәргә булышыр!

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***

**/Мөгаллим киңәше/**




## "MAX" кушымтасы куркынычмы?

Соңгы елларда элемтә өчен, эш өчен дә телефон кушымталарын бер-бер артлы чыгарып кына торалар. Кайберләрен үзебезнең телефоннарга куйганчы мең кат уйлап, шикләнеп тә йөрисең. Тик заманнан артка калмыйм дисәң, үзеңнән-үзең яңа агымга ияреп китәсең. Ә башкача булмый да.

Соңгы вакытта яңа булдырылган "MAX" мессенджерына карата бәхәс купты. Кемдер файдалы ди, кемдер куркыныч дип уйлый. Шуңа да карамастан, "MAX" бүгенге көндә үк инде бик популяр, аңа кушылучылар саны арткannan-арта бара. Әлеге мессенджер текст төзергә, тавыш хәбәрләрен һәм 4 гигабайтка кадәр файллар җибәрергә, шулай ук, катнашучыларның саны һәм бәйләнешнең озынлыгы буенча чикләүләрсез төркемле видеошалтыратулар ясарга да мөмкинлек бирә. Өстәвенә, сигнал начар булганда да шалтыратырга мөмкин!

Әмма "MAX" – аралашу өчен яңа, тулысынча үзебезнең ил мессенджеры гына түгел, ул бер урында күп бурычларны һәм мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкин булачак зур заманча платформа. Бу профильне "Дәүләт хезмәтләре"нә (ГОСУСЛУГИ) бәйләргә һәм кушымтадан чыкмыйча күп кенә мәсьәләләрне хәл итәргә була: акча күчерергә, "коммуналка" өчен түләргә, табибка язылырга, такси чакыртырга, үз каналыңны ачарга һәм популяр блогерга әверелергә мөмкин булачак.

Бу кушымтада файдалы функция дә бар– "Хәвефсез режим" – беренче чиратта өлкәннәр өчен бик кирәкле функция. Кыска гына итеп әйткәндә, "Хосусыйлык" бүлегендә, әгәр сез һәм сезнең әңгәмәдәшегез бер-берегезнең телефон китабында булса, бары тик "үзебезнекеләр" белән генә шалтыратышырга мөмкинлек бирүче көйләү бар. Билгесез номерлар сезгә шалтырата алмаячак.Тиздән әлеге кушымтаны барлык яңа телефоннарга урнаштырачаклар. ***(Ахыры икенче биттә)***

***(Башы беренче биттә)***Теркәлү өчен йөкләтеп кенә аласы. МАХска берьюлы бернечә җайланмадан да керергә мөмкин булачак.Нәтиҗә ясап әйткәндә, “МАХ” Россия платформасы аралашу, видео белән ”күрешеп сөйләшү” өчен заманча мөмкинлекләр тудыра. Тулысынча бушлай мөмкинлекләре белән мобиль элемтәдә сизелерлек экономияләргә ирешеп булачак. Бу кушымта әти-әниләр өчен файдалы. Балалары белән аралашу, мәктәп яңалыкларыннан хәбәрдар булу өчен уңай шарт.Иң уңайлысы- ул чит номерларны кертми. Бу бүгенге куркыныч тудырган кырыкалдарлардан саклавы белән мөһим.


**Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**

***/Мәктәп тормышы/***

## *Сентябрь вакыйгалары*



4нче сентябрьдә мәктәптә **ата-аналар җыелышы** булып узды. Җыелышта яңа уку елы башлануга бәйле агымдагы мәсьәләләр каралды. Директор Рафик абый Насыйров тарафыннан узган уку елына нәтиҗәләр ясалды һәм яңа уку елына бурычлар куелды. Фәнис абый Хәснуллин әти-әниләргә “МАХ” кушымтасы турында аңлатып узды. Алсу апа Сафиуллина быелгы уку елында балаларны кайнар ризык белән тукландыру тәртибен һәм бәяләрен әйтеп узды. Ә шулай ук директор киңәшчесе Гөлфия апа Әхмәтҗанова финанс мошенниклыгына каршы тору һәм наркотикларның законсыз әйләнеше турында мәгълүмәт бирде.



5нче сентябрь 8-9 сыйныф укучылары өчен МХОдан ялга кайткан авылдашыбыз – танк командиры Хәснуллин Азат Шәриф улы катнашуында **батырлык дәресе** булып узды. Бу дәрес аша укучылар моннан 80 ел элек булган Бөек Ватан сугышы һәм бүгенге көндә Украинада барган СВО вакыйгалары кеше күңеленә тирән яра салуын һәм чыннан да тарихка кереп калырдай вакыйга икәненә инандылар.



1965 елдан башлап һәр елны 8 сентябрьдә Халыкара белемлелек тарату көнен билгеләп үтү кабул ителгән. 1-4 сыйныф укучылары өчен **"А дан Я га кадәр"** дигән чара оештырылды. Укучылар алдына сайлап алынган хәрефкә мөмкин кадәр күбрәк сүз төзү бурычы куелды. Ә 6-9 сыйныф укучылары **"Гаилә юлы"** темасына тоталь диктант яздылар. Диктант язганнан соң, үз гаиләләрендә булган традицияләр белән уртаклаштылар.



11нче сентябрь көнне мәктәбебездә **Фашизм корбаннарын искә алу** көненә багышланган күңелле тетрәндергеч чара узды. Бу бөтендөнья коточкыч сугышта һәлак булган миллионнар алдында баш игән көн. Тәрбия буенча директор киңәшчесе Гөлфия апа 9 сыйныф укучылары белән бергә "Зоя истәлеге"дигән театральләштерелгән чыгыш әзерләделәр.Алар Зоя Космодемьянскаяның тормышы һәм батырлыклары турында сөйләделәр. Бу тарих–дәреслектәге бит кенә түгел. Бу бөек батырлык, фидакарьлек һәм Ватанга мәхәббәт үрнәге. Сугыш чоры вакыйгалары безне ата-бабаларыбызның тыныч күк йөзе өчен түләгән бәясе турында уйланырга мәҗбүр итә. Шуңа күрә безгә бу истәлекне саклау һәм аларның батырлыгына лаеклы булу бик мөһим. Каһарманнарга мәңгелек хәтер! Зоя Космодемьянская һәм фашизмның миллионлаган башка корбаннары турындагы истәлек безнең йөрәкләрдә калачак.



19нчы сентябрь көнне мәктәптә **“Беренчеләр”** хәрәкәтенең мәктәптәге беренчел бүлекчәсе рәисен сайлау булып узды. “Беренчеләр” советы рәисе – мәктәп укучылары арасында бәйләүче буын. Улхәрәкәт координаторы булараk, тәкъдимнәрне, идеяләрне һәм проблемаларны ишетергә, шулай ук аларны хәл итүдә ярдәм итәргә тиеш.Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беренчел бүлекчә советы рәисе итеп 8 сыйныф укучысы Ләйсән Закирова билгеләнде. Аны җиңүе белән котлап, җаваплы вазифасында уңышлар телибез.

***Мәгълүматны “Мәктәп хәбәрчесе” редколлегиясе әзерләде***



***/Безгә кунак килде/***

## *ТНВ – бездә, без – ТНВда*

Яңа уку елы башланып та җитмәде, көтмәгәндә безнең мәктәпкә ТНВ каналыннан үзенең командасы белән журналист Илдар Сафиуллин килде. Телевидение хезмәткәрләренең безгә килү максаты – барлык фәннәр дә саф татар телендә укытыла торган милли татар мәктәбен өйрәнү һәм башкаларга таныту иде.

Без кунакларыбызны милли татар киемнәре киеп, милли ризыгыбыз чәк-чәк белән каршы алдык.Алар мәктәбебезне җентекләп өйрәнделәр.Иң элек мәктәп коридорында һәркемгә ачык булган музеебызны караудан башладылар. Директорыбыз Рафик абый журналистларны авыл һәм мәктәп тарихыбелән таныштырды. Аннан соң районыбызның мәгариф бүлеге җитәкчесе Рәмзия апа Салиховнадан район мәгариф системасы турында интервью алдылар. 9нчы сыйныфтан Вәлиев Ибраһим бик тәэсирле итеп Хәсән Туфанның “Урман” шигырен сөйләде. Нәни балалар янында – бакча төркемендә дә, мәктәптәге дәресләрдә дә булдылар.

Шундый күренекле кунаклар килгәч, безнең дә аларга сорау бирәсебез килде. Үзебезне мәктәп гәзите редколлегиясе итеп таныштыргач, гәзитебез белән дә кызыксынып киттеләр. Үзара сорау-җавап алыштык дияргә була. Чын журналистлар белән очрашу күп нәрсәгә күзне ача икән ул. Чынлап торып кызыксынып киттек әле мәкалә язулар, телевидение хезмәте белән. Анда күпме кеше эшләгәнен, никадәр филиаллары барлыгын да белештек. Шуннан соң Илдар абый безнең гәзитебезнең нинди форматта чыгуы, нинди шартларда бастыруыбызны төшереп алды.

Шулай итеп, ТНВ командасы безнең мәктәптән бик күп мәгълүмат туплап китте. Озак та үтмәде, безнең турыдагы репортаж “Татарлар”тапшыруында экраннарга да чыкты. Әгәр күрми калган булсагыз, мәктәбебезнең ВК дагы төркеменнән карый аласыз.

***Ләйсән Закирова, VIII сыйныф укучысы***



## *“Ватаным Татарстан” гәзите бездә кунакта*

Сентябрь башында безнең мәктәптә күңелле бер очрашу булып узды. ТНВдан килгән кунакларны озаткан гына идек, 8 нче сентябрьдә республикабызның абруйлы басмасы – "Ватаным Татарстан" газетасы журналистлары килде. Әлбәттә, без мондый кунакларга бик шат. Беренчедән, чын телевидение хезмәткәрләре белән, икенчедән, танылган редакция журналистлары белән аралашу – безнең мәдәни үсешкә бер зур адым гына!

Бу мөмкинлекне файдаланып без дә "Ватаным Татарстан" битләрендә мәктәп турындагы язмалары белән танылган журналист Сәрия Мифтаховага белән аларның эшләре, фикерләре турында бернічә сорау бирдек.

*- Хәерле көн кунаклар. Без сезнең килүегезгә бик шатбыз. Сезнең безнең мәктәпкә килүегезнең максаты нинди?*

***- Без сезнең Түбән Майна авылы мәктәбе турында ишетеп беләбез. Мондый милли мәктәпнең ничек яшәве, укучылары, нинди тәрбия, гомумән, милли мохитның нинди булуы безне кызыксындырды.***

*- Бер мәкаләлә язу өчен шундый зур юлларга кузгаласызмы?*

***- Ерак юлларга йөрергә бик яратабыз. Татарстанның барлык районнарында булганыбыз бар. Мондый сәфәрләр халкыбызның яшәеше, аның фикерләвен, нинди уйлар белән яшәвен белергә ярдәм итә.***

*- Мәкаләләр язу өчен, әлбәттә, күп белемнәргә ия булу кирәк.Ә сезнеңчә иң төп сыйфат ул нинди?*

***- Хәзерге вакытта журналист оператив булырга һәм төпчелә белергә тиеш. Иң мөһиме хәзерге вакытта ул –җитезлек.***

*- Ә сез бер санны әзерләү өчен күпме вакыт сарыф итәсез?*

***- Белгәнегезчә, безнең газета атнасына өч тапкыр чыга. Бер газетны чыгару өчен 1-2 көн сарыф ителә. Бездә бик күп журналистлар эшли, аларның һәрберсенең темасы билгеләнгән. Ул шул язманы өлгертергә тиеш.***

*-Без дә үзебезнең кечкенә генә гәзитебезне чыгарабыз. Безгә нинди киңәшләр бирер идегез.*

***-Мондый эш алып бару, беренчедән, сезнең тел байлыгызны арттырып. Тиз эшләргә, тиз генә күргән хәлләргә нәтиҗә ясап, тиз арада мәкалә дә язарга өйрәнергә кирәк.***

Шулай итеп, без чын журналистлар тормышы белән таныштык. Бу очрашу безнең өчен бик файдалы һәм кызыклы булды. Без танылган газетаның профессионал журналистларыннан күп яңа белем алдык. Аларның эш тәҗрибәсе безнең үз мәктәп басмасыбызны эшләүдә зур ярдәм булыр дип өметләнәм.

***Кәүсәр Насыйрова, VIII сыйныф укучысы***